# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш авылында 2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**30.03.2024 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгының «Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында 2024 елның 18 мартындагы 1 номерлы карары белән «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында гражданнар Җыенының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 16.11.2023 ел, №1 «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 16.11.2023 ел, №2 «2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү» турында карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Минзәләбаш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында гражданнар Җыенының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 16.11.2023 ел, №1 «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 16.11.2023 ел, №2 «2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарларга түбәндәге редакциядә чараларга үзгәрешләр кертергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Минзәләбаш авылы халкының күпләп ял итү урынын төзекләндерү һәм аңа якын территорияне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эскәмияләр ясау, милли спорт төрләре өчен спорт җиһазлары урнаштыру, стойка ясау һәм баннер сатып алу, сәхнә һәм трибуна ясау, территорияне электрлаштыру);

2) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (ИДН (ясалма юл тигезсезлеге) (килешү буенча эш өчен түләү) Яңа Минзәләбаш торак пунктында Яңа Минзәләбаш урамында);

3) Яңа Минзәләбаш торак пунктында Яңа Минзәләбаш урамында терәкләр белән өстәмә яктырту нокталары урнаштыру (килешү буенча эшләрне сатып алу, урнаштыру, түләү) ;

4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Яңа Минзәләбаш торак пунктында янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру һәм тоту (килешү буенча эш өчен түләү));

5) яр буе зоналарын, сулыкларны (Яңа Минзәләбаш урамындагы Яңа Минзәләбаш торак пунктында Минзәлә елгасының яр буе зонасын чистарту)чистарту;

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Минзәләбаш авылының мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы»
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
МБ башлыгы Р.Ә. Каримов